| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2018 Казан ш. № 10-128/кс

Эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга 2019 елга тарифлар билгеләү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифларны әлеге карарга кушымтада каралган календарь бүленеш буенча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, һәркем өчен ачык булырга тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 7 декабрендәге 10-128/кс
номерлы карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар өчен 2019 елга, календарь бүленештә күрсәтеп, эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) калдык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Ташландык суны чыгаруга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | |
| 1 | "РСК" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | |
| 1.1 | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 19,97 | 20,56 | 19,01 | 19,58 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифларны күрсәткәндә НДС исәпкә алынмаган) | 16,64 | 17,13 | 15,84 | 16,32 |
| | Яңа Чишмә муниципаль районы | | | | |
| 2 | "Яңа Чишмә ТКХ" МУП** | | | | |
| 2.1 | Яңа Чишмә, Петропавел, Акъяр, Красный Октябрь, Әдәмсә, Черемухово, Тубылгытау, Чабаксар авыл җирлекләре кулланучылары өчен | 24,47 | 25,12 | | |
| 2.2 | Ленино авыл җирлегенең Коршково авылы, Екатерина авыл җирлегенең Яңа Иванаево авылы, Архангел, Акбүре, Буревестниковский авыл җирлекләре кулланучылары өчен | 24,18 | 24,92 | | |
| 2.3 | Яңа Чишмә авыл җирлеге кулланучылары өчен | | | 29,49 | 30,40 |
| | Нурлат муниципаль районы | | | | |
| 3 | «Промочистка» ҖЧҖ | | | | |
| 3.1 | Биләркүл, Гәйтән, Егоркино, Ялаур, Заречный, Кычытканлы, Мамык, Би Күле, Урта Камышлы, Төрнәс, Чулпан, Иске Чаллы, Киекле, Әхмәт, Әмзә, | | | | |

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) калдык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Ташландык суны чыгаруга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр |
| | Биккол, Колбай-Мораса, Сәләнгеш, Иске Әлмәт, Тимерлек, Якушкино, Фома авыл җирлекләре кулланучылары өчен | | | | |
| | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 25,50 | 26,18 | | |
| | Башка кулланучылар (тарифларны күрсәткәндә НДС исәпкә алынмаган) | 21,25 | 21,82 | | |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә.
<**>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге